Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 19-1**

Бәтке авылы 16 декабрь 2016 ел

"2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджеты турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 – ФЗ Федераль законның 35 статьясындагы 10 өлешенең 2 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 12 һәм 14-15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 8 өлешенең 2 пункты, 19 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты һәм 2 пункты нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге Уставы, Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советы Карар итте:

1нче маддә. 1.Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджетының 2017 елга төп характеристикаларын расларга: 1) Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2 976,6 мең сум; 2) Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2 976,6 мең сум; 2. Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджетының 2018 елга һәм 2019 елга төп характеристикаларын расларга:

1)2018 елга Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлегенең фаразлана торган гомуми керем күләме 3009,3 2019 елга 3058,3 мең сум күләмендә; 2) 2018 елга Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 3009,3 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә 73,4 мең сум һәм 2019 елга 3058,3 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 149,2 мең сум; 3. Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын 2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар план чорына 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә

2нче маддә.

1. 2017 елның 1 гыйнварына Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның 0,0 мең сум күләмендә югары чиген билгеләргә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә. 2. 2018 елның 1 гыйнварына Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның 0,0 мең сум күләмендә югары чиген билгеләргә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

3. 2019 елның 1 гыйнварына Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның 0,0 мең сум күләмендә югары чиген билгеләргә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә. 4. Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге муниципаль бурычының чик күләмен билгеләү: 2017 елда 0,0 мең сум күләмендә; 2018 елда 0,0 мең сум күләмендә; 2019 елда 0,0 мең сум күләмендә. 5. Бәтке авыл җирлегендә 2017-2019 елларда заем алу планлаштырылмый. Моны исәпкә алып, 2017-2019 елларга Муниципаль бурыч алулар программасы төзелми.

3 нче мәддә.

1. Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджетында 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына керемнәрнең фаразлана торган күләмен 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 нче маддә

1.Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген 3 нче кушымта нигезендә расларга

5.Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге бюджеты Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органы белән төзелгән килешү нигезендә үтәлә.

Бу карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Бәтке авылы,Ленин урамы,4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

“Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов

СОВЕТ БЕТЬКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000186 БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ